Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 6**

с. Шумково                                                  2020 елның 1 июнь

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шумково авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма (сәяси фиркадән тыш) белән идарә итүдә ялгыз башкарма орган сыйфатында катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 август 8 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2019 елның 16 декабрендәге “Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым законнарына үзгәрешләр кертү хакында”432-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Шумково авыл җирлеге”муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма (сәяси фиркадән тыш) белән идарә итүдә ялгыз башкарма орган сыйфатында катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 август 8 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Муниципаль хезмәткәргә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

а) сәяси фирка,һөнәри берлек органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте гомуми җыелышында катнашу;

б)Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиле рөхсәте белән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси фирка, һөнәри берлек органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте гомуми җыелышында катнашудан гайре);

в) Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә (тәкъдим итү) күрсәтү (яклау);

г)гамәлгә куючысы (акционеры, оештыручысы) булыпмуниципаль берәмлек торган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарындамуниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү (тәкъдим итү);

д)федеральзаконнардакаралганбашкаочраклар.”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карар рәсми төстә игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Башлыгы А.Р. Шәйдуллин

СОВЕТ ШУМКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000845 ШУМКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ